# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру тәртибе турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 24 февралендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасында транспорт инфраструктурасы объектларында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар (алга таба – гавами чара) уздыруда катнашуга Россия Федерациясе гражданнарының конституциячел хокукларын гамәлгә ашырганда шартлар тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

2. Әлеге Закон «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 8 статьясындагы $3^1$ өлеше нигезендә гомуми кулланылыштагы транспорт өчен файдаланыла торган һәм Федераль законның 8 статьясындагы 2 өлеше нигезендә гавами чара уздыру тыелган урыннарга карамый торган транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру тәртибен җайга сала.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр**

1. Әлеге Законда төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланылалар.

2. Транспорт инфраструктурасы объектлары – трамвай һәм эчке су юллары, контакт линияләре, автомобиль юллары, тоннельләр, эстакадалар, күперләр, вокзаллар, автобус станцияләре, метрополитен, елга портлары, порт чаралары, гидротехник корылмалар, аэродромнар, аэропортлар, элемтә, навигация һәм

транспорт чаралары хәрәкәте белән идарә итү системалары объектлары, шулай ук транспорт комплексы эшен тәэмин итүче башка биналар, корылмалар, җайланмалар һәм җиһазлар керә торган технологик комплекс.

3 статья. **Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру турында хәбәрнамә бирү тәртибе**

Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру турында хәбәрнамә «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында хәбәрнамә бирү тәртибе хакында» 2006 елның 16 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) билгеләнгән тәртиптә бирелә.

4 статья. **Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру тәртибе**

1. Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру законнар таләпләрен үтәп гамәлгә ашырылырга тиеш.
2. Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чараны оештыручы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән, транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чаралар уздыру турында хәбәрнамә тапшырыла торган органнарга (алга таба – вәкаләтле органнар) гавами чара (бер катнашучы уздыра торган җыелыш һәм пикеттан тыш) уздыру хакында Федераль законда билгеләнгән срокларда язма рәвештә хәбәрнамә җибәрә.
3. Вәкаләтле органнар транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру турында хәбәрнамә алганнан соң – аны теркәү көнендә, ә хәбәрнамә 16 сәгатьтән соң кергәндә – киләсе эш көненең беренче яртысында хәбәрнамәнең күчермәсен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органына җибәрә.
4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча вәкаләтле органнарга транспорт инфраструктурасы объектында гавами чара уздыруның мөмкин булуы яисә мөмкин булмавы турында дәлилләнгән бәяләмә белән, шул исәптән транспорт инфраструктурасы субъекты фикерен исәпкә алып, рәсми җавап җибәрә.
5. Транспорт инфраструктурасы объектында гавами чара уздыру турында уңай карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле органнар гавами чараны оештыручыга бу гавами чараны уздыруда ярдәм итү максатларында вәкаләтле вәкил билгелиләр. Вәкаләтле вәкилне билгеләү язма күрсәтмә белән рәсмиләштерелә, анда транспорт инфраструктурасы объектында гавами чараны уздыру буенча аның хокуклары һәм бурычлары күрсәтелә. Вәкаләтле вәкилне билгеләү турындагы күрсәтмәне вәкаләтле органнар өч эш көне эчендә гавами чараны оештыручыга җибәрәләр.
6. Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру барышында транспорт инфраструктурасы объектларына зыян китерү куркынычы яный торган гамәлләр кылу тыела.

7. Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруның билгеләнгән тәртибен транспорт чараларына зыян салуга яисә аларны юкка чыгаруга китерерлек итеп бозган очракларда гавами чара оештыручылар китерелгән зыянны Россия Федерациясе законнары нигезендә кайтарырга тиеш.

5 статья. **Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү**

1. Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турында нигезләнгән тәкъдим Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органы тарафыннан вәкаләтле органнарга түбәндәге очракларда җибәрелә:

1) транспорт инфраструктурасы объекты авария хәлендә булса һәм аның территориясендә гавами чара уздыру гавами чарада катнашучыларның сәламәтлегенә һәм иминлегенә куркыныч тудырса;

2) гавами чара планлаштырыла торган вакытка транспорт инфраструктурасы объектында ремонт эшләре башкарылса;

3) гавами чара уздыру транспорт инфраструктурасы объектыннан гражданнарның файдалануы өчен каршылык (чикләү) тудырса яисә транспорт инфраструктурасы объектларында транспорт чаралары хәрәкәтен тулаем (өлешчә) туктатуны таләп итсә.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юл хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органының транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруның мөмкин булмавы турында бәяләмәсен алганнан соң вәкаләтле органнар гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турында гавами чара оештыручыга өч көн эчендә нигезләнгән тәкъдим җибәрәләр.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2011 елның 19 марты
№ 4-ТРЗ